ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 16 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге территориясендә Горшково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны Горшково авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- Болын урамы, Заозерная урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, су анализы өчен түләү);
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Ленино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// novosheshminsk. tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка танытырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы М.Г.Дубровина